Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР № 6-2

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 27 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2014 елның 18 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 07 июлендәге 305-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2014 елның 18 октябрендә , 9 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 07.11.2014 ел, №12, 31.07.2015 ел, №13, 26.06.2017 ел, №4-1, 20.06.2017 ел, № 3-2, 11.02.2020 №2-2, 07.09.2020 №7-3 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 2 абзацында “, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен куллану” сүзләрен өстәргә.

1.2. 4 пункттагы “Беренче квартал үткәннән соң, аванс түләүләрен түләү вакыты 15 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал тәмамланганнан соң 15 августтан да соңга калмыйча һәм өченче квартал тәмамланганнан соң 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча башкарыла. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның салым чорына җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Ленин ур., 48А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Балык  Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Таҗетдинов